БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
17 июль 2024 ел

**КАРАР**
№ 262

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Салавыч авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге территориясенең шәһәр төзелешен планлаштыруны гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 нче статьясына, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14,15 статьяларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына нигезләнеп, гавами тыңлаулар һәм килештерү комиссиясе нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2022 елның 15 декабрендәге 162 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Салавыч авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең генераль планына, түбәндәге редакциядә бәян итеп, кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге башкарма комитетына:

- әлеге карарның 1 пункты белән кабул ителгән генераль план нигезендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашырырга;
- Салавыч авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрен күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертергә;
- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Салавыч авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турындагы карарны территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасына йөкләүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Балтач муниципаль районы Башлыгы урынбасары,
Балтач район Советы рәисе урынбасары Н.Н.Сабирҗанов